КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 4 ноябрь г.Казань № 993

Метрополитеннан файдалану
кагыйдәләрен раслау турында

«Урамнан тыш транспорт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 7 һәм 10 статьялары, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Метрополитеннан файдалануның бертип кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 26 октябрендәге 386 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Метрополитеннан файдалану кагыйдәләрен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 4 ноябрь, 993 нче
карары белән расланды

# Метрополитеннан файдалану кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Метрополитен – пассажирлар өчен куркынычлыгы артык дәрәҗәдә булу сәбәпле, эксплуатацияләгәндә аерым игътибар таләп итә торган гомуми файдаланудагы шәһәр пассажирлар транспортының төп төрләреннән берсе. Бу кагыйдәләрне кулланышка кертүнең максаты – пассажирларга хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм культурасын арттыру, пассажирлар йөртүләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм метрополитен мөлкәтен саклау.

1.2. Метрополитеннан файдалану кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) метрополитенда пассажирлар йөртүләрне һәм кул букчаларын алып баруны оештыру тәртибен, метрополитенда пассажирлар йөртүләр һәм кул букчаларын алып бару шартларын, шулай ук метрополитенның күчмә составындагы һәм станцияләрендәге пассажирларга мәгълүмат бирүгә карата таләпләрне билгели.

1.3. Бу Кагыйдәләр метрополитенның бөтен территориясендә гамәлдә һәм аның территориясендә булган барлык затлар өчен мәҗбүри булып тора.

1.4. Метрополитен инфраструктурасы объектларына станцияләр һәм алар составына керә торган станцияләр арасындагы тоннельләр, ярдәмче электр станцияләре мәйданчыклары, депо, вентиляция шахталары һәм киосклар, метрополитенның башка җир һәм җир өсте корылмалары керә.

1.5. Метрополитен территориясендәге затлар бер-берсенә ихтирамлы, метрополитен корылмаларына һәм җиһазларына карата сакчыл мөнәсәбәттә булырга, чисталыкны һәм җәмәгать тәртибен сакларга, шулай ук бу Кагыйдәләрне үтәргә тиеш.

1.6. Пассажирлар йөртүләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм террорчылыкка каршы чараларны тормышка ашыру максатларында, метрополитен станцияләрендә техник чаралар белән тәэмин ителгән пассажирларны һәм багажны сайлап тикшерү пунктлары җиһазландырылган.

1.7. Бу Кагыйдәләр метрополитен поездлары вагоннарында һәм станцияләрендә метрополитенны эксплуатацияләү өчен җаваплыларның телефон номерларын һәм адресларын күрсәтеп урнаштырылырга тиеш.

## II. Метрополитенда пассажирлар йөртүләрне һәм кул букчасын алып баруны оештыру тәртибе

2.1. Метрополитенда пассажирлар йөртү һәм кул букчасын алып бару пассажир йөртү шартнамәсе нигезендә даими йөртүләр маршрутлары буенча метрополитенда пассажир йөртү һәм кул букчасын алып бару йөкләмәсен үз өстенә алган юридик зат

яки индивидуаль эшмәкәр (алга таба – пассажирлар йөртүче) тарафыннан оештырыла.

2.2. Метрополитенда даими йөртүләр маршрутлары муниципаль берәмлекнең вәкаләтле башкарма комитеты органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә ачыла, үзгәртелә, ябыла.

2.3. Метрополитенда пассажирлар йөртү һәм кул букчасын алып бару муниципаль берәмлекнең вәкаләтле башкарма комитеты органы тарафыннан расланган транспорт хезмәте күрсәтү графигы (расписаниесе) нигезендә пассажирлар йөртүче тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиеш.

2.4. Даими йөртүләр маршрутлары буенча билгеләнгән нормалардан тыш пассажирлар йөртүгә һәм кул букчасын алып баруга тарифлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2.5. Метрополитен станцияләре пассажирлар керү һәм чыгу өчен көн саен 6 сәгать 00 минуттан 24 сәгать 00 минутка кадәр ачык була. Эш режимы, муниципаль берәмлекнең вәкаләтле башкарма комитеты органы белән килештереп, пассажирлар агымының күләменнән чыгып үзгәртелергә мөмкин.

2.6. Пассажирларның юл йөрү һәм кул букчасын алып бару бәясе өчен түләвен тикшерүдә тоту пассажирларның юл йөрү һәм кул букчасын алып бару бәясе өчен түләвен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле затлар тарафыннан башкарыла.

2.7. Станцияләрдә һәм вагоннарда транспорт куркынычсызлыгы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тәүлек буе видеокүзәтү, аудиога яздыру һәм видеога төшерү алып барыла.

## III. Метрополитенда пассажирлар йөртүләр һәм кул букчасын алып бару шартлары

3.1. Метрополитенда пассажир йөртү һәм кул букчасын алып бару өчен пассажир йөртү шартнамәсен төзү нигез булып тора.

3.2. Пассажир йөртү шартнамәсен төзү һәм йөрткән һәм билгеләнгән нормалардан тыш кул букчасын алып барган өчен түләүне башкару пассажирлар йөртүче тарафыннан пассажир тиешле түләүне (жетон, мәгълүматны электрон йөртә торган җайланмасы булган карта йә мәгълүматны электрон йөртә торган башка җайланма) гамәлгә ашырганнан соң бирелә торган юл йөрү документлары белән раслана. Жетонны жетон кабул итә торган җайланмага салырга, ә картаны турникеттагы электрон укый торган җайланмага куеп алырга кирәк. Түләүсез яки ташламалы юл йөрү хокукына ия булган пассажир белән юл йөрү шартнамәсен төзү әлеге зат тарафыннан мондый хокукны раслый торган документ күрсәтелгәннән соң гамәлгә ашырыла.

3.3. Эскалаторлар, лифтлар һәм күтәртү платформалары аларның техник эксплуатацияләү документлары нигезендә кулланылырга тиеш.

3.4. Станциягә поезд килгәннән соң вагонга кешеләрне утырту аннан алар чыгып беткәннән соң гына гамәлгә ашырылырга тиеш. Пассажирларны утырту һәм чыгару станциянең пассажирлар платформасы чикләрендә генә гамәлгә ашырыла.

3.5. Метрополитенда пассажирлар йөрткәндә пассажирлар йөртүче һәр пассажирга утыру өчен аерым урын бирергә тиеш түгел.

3.6. Балалар коляскаларын кулланып, балалар йөртү балаларның һәм пассажирларның иминлеген тәэмин итү шарты белән гамәлгә ашырылырга тиеш. Балалар коляскаларында булган балаларны эскалаторга, баскыч маршына яки вагонга керү алдыннан (вагоннан чыгу алдыннан) аларны кулга алырга кирәк, вагонга кергәндә (вагоннан чыкканда) башта колясканы этеп алып керергә (этеп чыгарырга) кирәк.

3.7. Бу Кагыйдәләрнең 3.2 нче пунктында күрсәтелгән юл йөрү документын рәсмиләштерү метрополитенда кулланыла торган юл йөрү өчен түләү системасы нигезендә башкарыла.

3.8. Пассажир йөртү һәм кул букчасын алып бару буенча хезмәтләр күрсәтү үткәрү пунктында тикшергәндә пассажирларның йөртү һәм кул букчасын алып бару буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләвен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле затның таләбе буенча гамәлдәге юл йөрү документын күрсәтмәгән затка, ә түләүсез яки ташламалы юл йөрү хокукыннан файдаланган очракта, шулай ук бу затның түләүсез яки ташламалы юл йөрүгә хокукын раслый торган документны күрсәтмәгән затка (мәгълүматны электрон йөртә торган җайланмасы булган карта рәвешендәге юл йөрү документында бу затның фотосурәте булган очраклардан тыш) гамәлгә ашырылмый.

3.9. Пассажирлар вагоннарда, станцияләрдә һәм станцияләр арасындагы юлларда онытып калдырылган, башка пассажирлар яки пассажирлар йөртүченең хезмәткәрләре тапкан әйберләр метрополитендагы полиция бүлеге хезмәткәрләренә тапшырыла.

3.10. Вагоннарда, станцияләрдә һәм станцияләр арасындагы юлларда булган пассажирларга мәгълүмат бирү Кагыйдәләрнең IV бүлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.11. Пассажирлар йөрткәндә һәм кул букчасын алып барганда пассажирлар йөртүче түбәндәгеләргә бурычлы:

1) пассажир йөртү һәм кул букчасын алып бару буенча хезмәт күрсәтү өчен түләгән пассажирларга, шулай ук түләүсез юл йөрү хокукына ия булган затларга әлеге хезмәтләрне күрсәтергә;

2) пассажирларны йөртә башланганга кадәр пассажирның юл йөрү документын сатып алу мөмкинлеген тәэмин итәргә;

3) пассажирның килгән станциядән чыгу мөмкинлеген мондый станцияләрне пассажирлар керү өчен япканнан соң, шул исәптән ишекләрне һәм турникетларны ачу, технологик җайланмалар (лифтлар, эскалаторлар һәм күтәртү платформалары) эшен 10 минут эчендә тәэмин итәргә;

4) станцияләрдә һәм вагоннарда пассажирлар йөртүче хезмәткәрләренең пассажирлар белән элемтәгә керү җайланмаларын эш хәлендә тотырга;

5) пассажирлар йөри торган юлда биеклеге 210 сантиметрдан түбән булган үтү юлларына сигнал бирә торган язулар һәм махсус тамгалар куярга һәм (яки) мондый йөри торган юлларны йомшак әйберләр белән җиһазландырырга.

3.12. Инвалидлар арасыннан булган пассажирларга юл йөрү һәм кул букчасын алып бару буенча хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеге пассажирлар йөртүче тарафыннан

инвалидлар арасыннан булган пассажирлар өчен инфраструктура объектларыннан һәм күрәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге шартларын тәэмин итү, шулай ук шул ук вакытта «Урамнан тыш транспорт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 2 өлеше белән билгеләнә торган кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибе нигезендә кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибе нигезендә тәэмин ителергә тиеш.

3.13. Пассажирлар йөртүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) пассажир тарафыннан бу Кагыйдәләр үтәлмәгәндә пассажир йөртү шартнамәсен өзәргә;

2) пассажирдан бу Кагыйдәләрне һәм транспорт куркынычсызлыгы турындагы Россия Федерациясе законнарын үтәүне таләп итәргә;

3) пассажирларның аерым категорияләренә, шул исәптән өлкән яшьтәге затларга, күпбалалы гаиләләргә, бала (балалар) белән баручы ялгыз аналарга, 10 яшькә кадәрге балалары булган ата-аналарга озатып баруны һәм ярдәм күрсәтүне оештырырга;

4) пассажир белән бергә баручы балаларны түләүсез йөрткәндә мондый пассажирдан йөртү һәм кул букчасын алып бару буенча хезмәт күрсәтүләр өчен пассажирларның түләвен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле затка баланың яшен раслый торган документларны (туу турындагы таныклыкны яки ата-аналарның бала туу турында язылган паспортны) күрсәтүне таләп итәргә.

Түләүсез йөрү хокукына ия булган бала (балалар) белән баручы, бала (балалар) яшен раслый торган документны (документларны) күрсәтмәгән пассажир мондый баланың (балаларның) юл йөрү өчен Кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә түли;

5) гамәлдә булмаган һәм ясалма билгеләре булган купюралар, жетоннар яки документлар (шул исәптән транспорт карталарын) күрсәтү вакыйгаларын тикшерү өчен метрополитенда полиция бүлеге хезмәткәрләрен җәлеп итәргә.

3.14. Пассажир түбәндәгеләргә бурычлы:

1) пассажирлар йөртүче хезмәткәрләренең Кагыйдәләрне һәм транспорт куркынычсызлыгы турындагы Россия Федерациясе законнарын үтәү буенча таләпләрен башкарырга;

2) пассажирлар йөртүче хезмәткәрләренә, метрополитендагы полиция бүлеге хезмәткәрләренә законсыз катнашу акты кылу куркынычын барлыкка китерә торган вакыйгалар яки гамәлләр турында хәбәр итәргә;

3) үткәрү пунктлары аша узганга кадәр юл йөрү документын сатып алырга;

4) үткәрү пунктлары аша узганда әлеге затның түләүсез яки ташламалы юл йөрү хокукын раслый торган документны күрсәтергә.

Ташламалы юл йөрү хокукын бирә торган документлар кул букчасын алып бару өчен билгеләнгән тариф нигезендә түләнергә тиешле кул букчасын түләүсез алып бару хокукын бирми;

5) тиз ватыла, кадый һәм кисә торган предметларны, чаңгылар һәм тимераякларны, кискен өлешләре ачык булган бакча коралларын, шулай ук сноубордлар, җыелма торган велосипедларны чехоллар белән (төреп) алып барырга;

6) хайваннарны (махсус укуын раслый торган документлары булганда күрү буенча инвалидларны озатып йөри торган муенчаклы баудагы этләрдән тыш) йөртү

өчен озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге буенча үлчәме 150 сантиметрдан артмаган читлекләрне яки төбе тоташтан булган башка җайланмаларны (мәсәлән, кәрҗин, тартма, контейнерлар) кулланырга;

7) пассажирларга әлеге станциягә керү ябылганнан соң 10 минут эчендә станциядән чыгырга;

8) пассажирлар йөртүче хезмәткәрләренә, метрополитендагы эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә онытылып калган әйберләр яки документлар табылу турында хәбәр итәргә;

9) вагонга кергәч, рюкзак яки сумканы җилкәдән салырга;

10) метрополитен станциясенә төшкәндә култыксага тотынырга;

11) башка пассажирлар хәрәкәте өчен комачаулык тудырмаска;

12) метрополитен инфраструктурасы объектлары территориясендә үз иминлеген тәэмин итү чараларын үтәргә.

3.15. Пассажир түбәндәгеләргә хокуклы:

1) юл йөрү документлары булганда үткәрү пунктлары аша узарга. Автомат булмаган үткәрү пунктлары балалар коляскалары, велосипедлар, этләр белән булган, коляскада йөри торган инвалидлар, йөкле хатын-кызлар, җиде яшьтән зуррак булмаган балалар өчен каралган;

2) электрон рәвештә күрсәтелгән юл йөрү документының реквизитлары турында, шул исәптән юл йөрү документының гамәлдән чыгу вакыты турында мәгълүмат алырга;

3) озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге буенча үлчәме 120 сантиметрдан артмаган кул букчасын бер урында өстәмә түләүсез алып барырга. Озын кул букчасының һәр берәмлек зурлыгы иң күбе 150 сантиметр;

4) түбәндәгеләрне өстәмә түләү алмыйча алып барырга:

үзәңә турыдан-турын якын тотып, зыян салуны булдырмау буенча барлык чараларны күреп, җиде яшьтән өлкәнрәк булмаган балаларны;

балалар коляскасын;

инвалид коляскасын;

чехол белән бер пар чаңгы, чехол белән тимераякларны;

балалар велосипедын, балалар чанасын;

төрелгән яки чехол белән музыка уен коралларын, бакчада кулланыла торган вак коралларны, балык тоту кармакларын (зурлыгы бу пунктның 3 нче пунктчасында күрсәтелгән күләмнән артмаган);

озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге буенча үлчәме 150 сантиметрдан артмаган читлекләрдә яки хайваннарның үзеннән-үзе чыгып китүен булдырмый торган, төбе тоташтан булган башка җайланмаларда йорт хайваннарын ;

5) пассажирлар йөртүче җитәкчелегенең язма бирелгән рөхсәт кәгазеннән соң өстәмә аппаратура кулланып, һөнәри фотога һәм (яки) видеога төшерүне гамәлгә ашырырга.

3.16. Эскалаторда барганда пассажир түбәндәгеләргә бурычлы:

1) култыксага тотынып, хәрәкәт юнәлеше буенча эскалаторның уң ягында йөз белән басып торырга, хәрәкәт иткән очракта, култыксага тотынып, хәрәкәт юнәлеше буенча эскалаторның сул ягыннан барырга;

2) баскычлардагы чикләү линияләренә аяк белән басмаска, эскалаторның хәрәкәтләнми торган өлешләренә сөялмәскә һәм кул букчасын сөямәскә, эскалатордан чыкканда тоткарланмаска;

3) эскалаторның хәрәкәтләнә торган тасмасы тарагына эләкмәс өчен өс киемнәренең озын чабуын, хуҗалык арбаларын, арба-сумкаларны бераз күтәрергә, үзеннән-үзе хәрәкәтләнеп китмәү максаты белән кул букчасының торышын тикшереп торырга;

4) балаларны кулыннан тотарга яки кулга алырга, аларга эскалаторның хәрәкәтләнми торган өлешләренә сөялергә рөхсәт итмәскә.

3.17. Пассажир вагонда булганда түбәндәгеләргә бурычлы:

1) басып барганда култыксага тотынырга;

2) билгеләнгән станциягә якынайганда вагоннан чыгу өчен алдан әзерләнергә;

3) инвалидларга, өлкән яшьтәге затларга, балалары булган пассажирларга һәм йөкле хатын-кызларга утыру өчен урыннар бирергә.

3.18. Платформада булганда пассажир түбәндәгеләргә бурычлы:

1) поездны көткәндә платформада уңайлы урын сайларга;

2) поезд туктаганда пассажирларның ирекле чыгуын тәэмин итү өчен вагоннар ишекләре янында урын бушатырга;

3) платформада шикле затлар, караусыз калдырылган чит предметлар булуы ачыкланганда бу турыда станция буенча кизү торучыга яки хокук саклау органнары хезмәткәренә кичекмәстән хәбәр итәргә кирәк. Шикле предметларны бетерү яки урыныннан күчерү буенча мөстәкыйль гамәлләр кылмаска кирәк.

3.19. Станцияләрдә һәм станцияләр арасындагы юлларда булганда пассажир метрополитен юлына кешеләр яки әйберләр төшүнең, төтен яки янгын чыгуның барлык очраклары, шулай ук пассажирларның яки поездларның хәрәкәте иминлегенә йогынты ясый торган хәлләр турында пассажирлар йөртүче хезмәткәренә хәбәр итәргә тиеш.

3.20. Пассажирларга түбәндәгеләр тыела:

1) кул букчасын йөртү өчен көпчәкле чаралар (озынлыгы, киңлеге һәм биеклегенең үлчәмнәре буенча күләмнәре 150 сантиметрдан артмаган чемоданнар, хуҗалык арбалары, арба-сумкалардан тыш) кулланырга;

2) пассажирлар йөртүче хезмәткәрләре рөхсәтеннән башка эшләми торган эскалатор буенча хәрәкәт итәргә;

3) эскалатор буенча йөгерергә, эскалатор баскычына, култыксасына һәм балюстрадасының ян өлешенә утырырга һәм әйберләр куярга, эскалаторның ян өлешләреннән һәм култыксасыннан шуып төшергә;

4) эскалатор мәйданчыкларында урнаштырылган киртәләрне, шулай ук пассажирлар йөртүче тарафыннан билгеләнгән башка киртәләрне алып куярга;

5) кичектергесез очраклардан тыш, эскалаторның «Тукта» сүндергечләрен (туктату таягын/төймәсен) кулланырга;

6) станцияләрдә поезд туктап беткәнгә кадәр платформа кырыендагы чикләү линиясенә керергә, метрополитен юлына төшәргә, метрополитен юлына төшкән предметларны мөстәкыйль күтәрергә, метрополитен юлларында чит предметлар урнаштырырга;

7) вагонның ишекләрен ябу турында тавыш белән мәгълүмат биргәннән соң вагонга керергә һәм вагоннан чыгарга, шулай ук вагон ишекләрен тулысынча ачканга кадәр керергә һәм чыгарга;

8) вагонда ишекләргә сөялергә, пассажирларга керергә һәм чыгарга комачауларга;

9) кул букчасы составында озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге буенча үлчәме 150 сантиметрдан артып киткән йә озынлыгы 150 сантиметрдан артып киткән предметлар (Кагыйдәләр белән билгеләнгән инвалид коляскаларыннан һәм башка предметлардан тыш) алып барырга;

10) поезд хәрәкәт иткән һәм туктаган вакытта вагонның ишекләрен ачарга, шулай ук аларны ачарга һәм ябырга комачауларга, поездны станциядән җибәрүне тоткарларга, ябык типтагы станцияләрдә автомат станция ишекләрен ачарга, аларны ачарга яки ябырга комачауларга;

11) корал һәм сугыш кирәк-яракларын (Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш), шартлаткыч матдәләр яки башка җайланмалар, Россия Федерациясе законнары белән транспорт куркынычсызлыгы зонасына күчүне тыю яки чикләү билгеләнгән предметларны һәм матдәләрне, шулай ук коррозияле һәм башка куркыныч матдәләр һәм көнкүреш газ баллоннарын алып барырга;

12) сасы ис чыгара торган кул букчасын һәм (яки) станцияләрне һәм вагоннарны яки пассажирлар әйберләрен пычрата торган кул букчасын алып барырга;

13) кул букчасын караучысыз калдырырга;

14) алкогольле һәм спиртлы продукция эчәргә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр кулланырга;

15) тәмәке тартырга, тәмәке куллану җайланмасын, никотин китерүнең җылытыла торган һәм электрон системаларын файдаланырга;

16) транспорт куркынычсызлыгын тәэмин итүнең техник чаралары эшләвенә комачауларга;

17) мотоциклларда, мопедларда, велосипедларда, самокатларда, роликлы тимераякларда һәм башка хәрәкәт итү чараларында (инвалид коляскаларыннан тыш), шулай ук спорт инвентарен кулланып хәрәкәт итәргә, пилотсыз очу аппаратларыннан файдаланырга;

18) метрополитен территориясендә аяк киемсез һәм (яки) өс киемсез булырга;

19) пычрата, сасы ис килә торган киемдә булырга;

20) пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырмый торган яки туктаткан поездларда булырга;

21) поезд түбәсендә, автототаштыру җайланмаларында һәм башка элементларында йөрергә һәм аларга менергә, поездларның кабиналарына керергә, шулай ук аларда юл йөрүне гамәлгә ашырырга;

2) парапетларда, киртәләрдә булырга, шулай ук алар аша сикереп чыгарга (аркылы чыгарга);

23) вагоннарның тышкы һәм эчке өслекләренә, шулай ук метрополитен инфраструктурасы объектларына язулар язарга, ябыштыргычлар беркетергә, сурәтләр ясарга, мәгълүмати һәм реклама материалларын урнаштырырга;

24) эшмәкәрлек эшчәнлеген һәм табыш китерә торган башка эшчәнлекне, шулай ук хәйрия эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен вагоннарны һәм метрополитен

инфраструктурасы объектларын пассажирлар йөртүче җитәкчелегенең язма рөхсәтеннән башка файдаланырга;

25) теләнчелек белән шөгыльләнергә;

26) вагоннарда һәм метрополитен инфраструктурасы объектларында музыка уен коралларын һәм тавышкөчәйткеч чараларыннан (ишетү аппаратларыннан һәм башка индивидуаль җайланмалардан (колакчыклардан) башка) пассажирлар йөртүче җитәкчелегенең язма рөхсәтеннән башка файдаланырга;

27) вагоннарда һәм метрополитен инфраструктурасы объектларында мәдәни, спорт, сәяси, дини һәм башка чараларны пассажирлар йөртүченең язма рөхсәтеннән башка үткәрергә;

28) вагоннарны һәм метрополитен инфраструктурасы объектларын чүпләргә һәм пычратырга, шулай ук ватарга;

29) метрополитенның җитештерү бүлмәләренә һәм киртәләп алынган территориясенә үтеп керергә;

30) вагоннарда һәм метрополитен инфраструктурасы объектларында учак ягарга, пиротехник җайланмалар (мәсәлән, фейерверклар, петардлар) кулланырга;

31) пассажирлар йөртүче хезмәткәрләренең хезмәт вазыйфаларын башкаруына комачауларга;

32) метрополитен эшенә комачаулый торган хокукка каршы гамәлләр кылуга йә аларны кылуны әзерләүгә охшаш булган гамәлләр (пассажирларның иминлегенә куркыныч яный торган вакыйгалар яки гамәлләр турында белә торып ялган хәбәрләр таратуны кертеп) башкарырга;

33) мәгълүматларны чыбыксыз тапшыру җайланмалары эшендә катнашырга;

34) пассажирларны, вагоннарны, станцияләр корылмаларын һәм җайланмаларын пычрата алган багаж, предметлар, азык-төлекләр (шул исәптән савыты ачык булган эчемлекләр һәм туңдырмалар) белән метрополитен территориясенә керергә.

## IV. Вагоннарда, станцияләрдә һәм станцияләр арасындагы юлларда булган пассажирларга мәгълүмат бирүгә карата таләпләр

4.1. Вагоннарда, станцияләрдә һәм станцияләр арасындагы юлларда пассажирларга мәгълүмат бирү максатларында пассажирлар йөртүче тарафыннан тавыш белән мәгълүмат бирү, интерактив схемалар, электрон таблолар, мониторлар, шулай ук схемалар, күрсәткечләр һәм басма форматтагы башка мәгълүмат кулланылырга тиеш.

4.2. Станцияләрдән чыгу юлларына пассажирлар йөртүче тарафыннан номер сугылырга тиеш.

4.3. Пассажирлар йөртүче муниципаль берәмлек яки метрополитенның тиешле станцияләре янындагы аның аерым территорияләре схемаларында (алга таба – территорияләр схемалары) станцияләрдән чыгу номерларын күрсәтүне, тимер юл станцияләрен, автовокзалларны, автостанцияләрне, елга портларын (булганда), гомуми файдаланудагы башка пассажирлар транспортының тукталыш пунктларын, планлаштыру структурасының һәм урам-юл челтәренең бу станциядән чыгу мөмкинлеге булган башка элементларын билгеләүне тәэмин итәргә тиеш.

4.4. Пассажирлар йөртүче территорияләр схемаларында гомуми файдаланудагы башка пассажирлар транспорты төрләре белән даими йөртүләр маршрутларының номерлары һәм (яки) юнәлешләре күрсәткечләрен урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

4.5. Метрополитен линияләренә пассажирлар йөртүче тарафыннан номер сугылырга тиеш.

4.6. Метрополитен линияләренең номерлары метрополитен линияләре схемаларында күрсәтелергә тиеш.

4.7. Йөртүче вагоннарда түбәндәгеләрне урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш:

1) станцияләр исемнәрен күрсәтеп, басма һәм (яки) электрон форматта метрополитен линияләре схемаларын;

2) балалары булган пассажирлар, инвалидлар, өлкән яшьтәге затлар һәм йөкле хатын-кызлар утыру өчен урыннар күрсәткечләрен;

3) Кагыйдәләрне яки алардан (шул исәптән пассажирларның хокуклары һәм бурычлары күрсәтелә торган) өземтәләрне;

4) вагонның инвентарь номерын.

4.8. Пассажирлар йөртүче вагоннарда поезд килә торган станциянең исеме, башка станцияләргә, метрополитен линияләренә бару мөмкинлекләре турында, маршрутның киләсе станциясе исеме (поездның соңгы маршрут станциясенә килү очрагыннан тыш) һәм башка станцияләргә бару мөмкинлеге турында мәгълүмат бирүне (тавыш белән яки тавыш белән һәм визуаль рәвештә) тәэмин итәргә тиеш.

4.9. Пассажирлар йөртүче станцияләрдә түбәндәгеләрне урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш:

1) станция исеме булган күрсәткечләрне;

2) станцияләр исемнәрен күрсәтеп, басма һәм (яки) электрон форматта метрополитен линияләре схемаларын;

3) Кагыйдәләрне яки алардан (шул исәптән пассажирларның хокуклары һәм бурычлары күрсәтелә торган) өземтәләрне;

4) территорияләр схемаларын;

5) станциядән планлаштыру структурасы һәм урам-юл челтәре элементларына чыгу юнәлешләренең һәм номерларының күрсәткечләрен;

6) метрополитенның башка станцияләренә һәм линияләренә аларның исемнәре яки билгеләмәләре күрсәтелгән юллар күрсәткечләрен;

7) метрополитенда юл йөрү бәясе турында мәгълүмат;

8) алып барырга (шул исәптән бушлай) рөхсәт ителгән кул букчасының урыннар саны һәм зурлыгы турында мәгълүмат;

9) билгеләнгән нормалардан тыш кул букчасын алып бару бәясе турында мәгълүмат;

10) транспорт хезмәте күрсәтү графигы (расписаниесе) һәм станциянең эш вакыты турында мәгълүмат.

4.10. Метрополитен станцияләрендә һәм вагоннарында пассажирлар йөртүче пассажирлар белән пассажирлар йөртүче хезмәткәрләренең элемтәгә керүе өчен җайланмалар урнаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

4.11. Станцияләр арасындагы юлларда пассажирлар йөртүче станцияләр арасындагы юл буенча пассажирларның станцияләргә бара торган юл күрсәткечләрен урнаштыруны тәэмин итәргә бурычлы.

4.12. Пассажирлар йөртүче станцияләрдә һәм станцияләр арасындагы юлларда пассажирлар йөртүченең пассажирларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән җиһазның төзек булмавы турында, шулай ук охшаш функциональ тасвирнамәләргә ия булган төзек җайланманың якын урнашкан урыннары турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә бурычлы.

4.13. Пассажирларга тавыш ярдәмендә һәм визуаль рәвештә мәгълүмат бирү өчен пассажирлар йөртүче тарафыннан рус һәм татар телләре кулланылырга тиеш.

Кагыйдәләрнең 4.7 – 4.9, 4.11 һәм 4.12 нче пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат бирү пассажирлар йөртүче тарафыннан инглиз телендә кабатланырга тиеш.